**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 30.06.2021** **№ 566**

# Башкарма комитетның 2021 елның 26 мартындагы 317 номерлы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча туры китерү максатларында, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 26 мартындагы 317 номерлы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 7 пунктында: «башлыгы» сүзен «Башкарма комитеты» сүзенә алмаштырырга;

2) III бүлекнең 1 пунктында:

а) 4 пунктчасында «максатчан» сүзен төшереп калдырырга;

б) 12 пунктчасында «Россия Федерациясе субъектының» сүзләрен «Татарстан Республикасының» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин